ИНСПЕКЦИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ
КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ
ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ | БОЕРЫК

19.06.2026 | Казан шәһәре | № под-71/26

Татарстан Республикасы Дәүләт Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә вазифа биләве вакытында дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау хакында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге 701-ПУ номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре биләгән вакытта үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук керемнәре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау хакында», 2009 елның 30 декабрендәге 702-ПУ номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» указлары нигезендә

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә вазифа биләве вакытында дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш

булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе боерыкларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә биләве коррупция куркынычы белән бәйле, биләве вакытында дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау хакында» 24.08.2016 ел, № 59 боерыгы;

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгының 24.08.2016 № 59 боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә биләве коррупция куркынычы белән бәйле, биләве вакытында дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә үзгәреш кертү хакында» 16.04.2019 ел, № 51 боерыгы

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Житәкчесе В. Р. Нәҗмиев

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 19.06.2026 № под-71/26 боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Дәүләт Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә вазифа биләве вакытында дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Вазыйфаларның югары төркеменең «җитәкчеләр» категориясендәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы:

Инспекция башлыгы.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары вазыйфаларының баш төркеменең «җитәкчеләр» категориясе:

Инспекция башлыгының беренче урынбасары;

инспекция башлыгы урынбасары;

инспекциянең территориаль органы җитәкчесе.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы төркеменең «җитәкчеләр» категориясе:

Инспекция Аппараты идарәсе башлыгы; Инспекция аппараты бүлеге башлыгы;

Инспекция аппараты бүлеге башлыгы урынбасары;

Инспекциянең территориаль органы җитәкчесе урынбасары;

Инспекциянең территориаль органы бүлеге башлыгы;

сектор мөдире.

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының әйдәп баручы төркеменең «белгечләр» категориясе:

әйдәүче киңәшче;

әйдәүче консультант;

консультант.

5. Вазыйфаларның өлкән төркеменең «белгечләр» категориясендәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы:

Әйдәп баручы белгеч-эксперт

6. Вазыйфаларның әйдәп баручы төркеменең «тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы:

Әйдәп баручы белгеч

7. Вазыйфаларның өлкән төркеменең «тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы:

1 разрядлы өлкән белгеч;

2 разрядлы өлкән белгеч;

3 разрядлы өлкән белгеч.